КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 7 июль г.Казань № 652

Татарстан Республикасының календарь планнарына кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктындагы «д» пунктчасы, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктындагы «д» пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының календарь планнарына кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 7 июль, 652 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының календарь планнарына кертелгән
рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын
Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау
тәртибе

1. Татарстан Республикасының календарь планнарына кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау тәртибе Татарстан Республикасының рәсми физкультура чаралары һәм спорт чаралары календарь планнарына (алга таба – Календарь планнар) кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын финанс белән тәэмин итү шартларын билгели.

2. Календарь планнарга кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәрү чыгымнарын финанслау тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында әлеге максатлар өчен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Тиешле елда Календарь планнарга кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын финанс белән тәэмин итү күләмнәре һәм шартлары физик культура һәм спорт үсешенең өстенлекле юнәлешләреннән, Календарь планнарга кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәрүгә акча чыгымнары нормаларыннан, шулай ук аларның оештыручылары тарафыннан расланган мондый чараларны үткәрү турындагы нигезләмәләрдән һәм (яки) регламентлардан чыгып билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән түбәндәгеләр финанслана:

Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе территориясендә һәм аннан читтә үткәрелә торган республика, төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү;

республика, төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара рәсми физкультура һәм спорт ярышларында, күнекмәләр ясау чараларында катнашучы спортчыларны, тренерларны, белгечләрне һәм башка категорияләрдәге затларны җибәрү.

5. Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе территориясендә һәм аннан читтә үткәрелә торган республика, төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештырганда һәм үткәргәндә түбәндәгеләр өчен түләү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү гамәлгә ашырыла:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр;

вакытлыча корылмаларны, урыннарны, мәйданнарны, футбол кырларын, транспортны кертеп, корылмаларда хезмәт күрсәтүләр (аренда, коммуналь һәм

эксплуатация чыгымнары, техник хезмәт күрсәтү, модернизацияләү, реновацияләү, объектларны әзерләү);

чаралар үткәрү өчен кирәкле техник чараларны һәм ярдәмче җиһазларны арендалау, сатып алу, шулай ук чара үткәрү регламенты нигезендә аларны монтажлау, сүтү, эшләтеп җибәрү һәм хезмәт күрсәтү;

чаралар үткәрү өчен полиграфия продукциясе әзерләү һәм сатып алу;

төрле чараларда катнашу өчен спорт командаларын командировкага җибәрү, чараларда катнашучыларның, бөтенроссия һәм халыкара иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең, чара үткәрү регламенты буенча булуы мәҗбүри булган техник белгечләрнең визаларын, яшәвен, туклануын, тәүлек акчасын һәм транспортта йөрүен рәсмиләштерү;

спортчылар, тренерлар, белгечләр һәм чара үткәрү регламенты кысаларында булуы кирәкле башка катнашучылар өчен кирәкле спорт инвентаре һәм экипировка сатып алу;

спорт судьялары, җәлеп ителгән белгечләр һәм хезмәт күрсәтүче персонал эшләре;

чаралар үткәрү өчен кирәкле вакытлыча, төрле төрдәге конструкцияләрне кертеп, урыннарны, транспорт чараларын, мәйданнарны, корылмаларны бизәү, шул исәптән чара үткәрү регламенты нигезендә аларны монтажлау һәм сүтү;

бүләкләү атрибутикасы, сувенир продукциясе һәм чәчәкләр әзерләү һәм сатып алу;

ачу һәм ябу тантаналарын, мәдәният программасын оештыру;

программа тәэминаты һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү, мәгълүмат-коммуникация технологияләре (электрон судьялык итү, электр челтәре инфраструктурасы белән җиһазлау/җиһазлап бетерү, телевизион һәм интернет трансляцияләр оештыру);

чараларда медицина хезмәте күрсәтү һәм аларны медик-биологик яктан тәэмин итү, ашыгыч ярдәм автомобиле хезмәтләре күрсәтү;

чараның куркынычсызлыгын тәэмин итү;

элемтә белән тәэмин итү;

чараларда катнашучыларны аккредитацияләү;

чараларда катнашучыларны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү;

чара үткәрү регламенты нигезендә чараларны оештыруга, үткәрүгә һәм аларда катнашуга турыдан-туры бәйле булган старт һәм оештыру кертемнәре.

6. Республика, төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара рәсми физкультура һәм спорт ярышларында, күнекмәләр ясау чараларында катнашучы спортчыларны, тренерларны, белгечләрне һәм башка категорияләрдәге затларны җибәргәндә түбәндәгеләр өчен түләү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү гамәлгә ашырыла:

спорт корылмалары, транспорт хезмәтләре күрсәтү;

спортчыларны, тренерларны, белгечләрне һәм башка катнашучыларны командировкага җибәрү, ярыш һәм күнекмәләр ясау чараларын үткәрү регламенты буенча булуы мәҗбүри булган катнашучыларның визаларын, яшәвен, туклануын, тәүлек акчасын һәм транспортта йөрүен рәсмиләштерү;

техник чаралар өчен ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү;

спортчыларны медик-биологик яктан тәэмин итү;

ярышларда һәм күнекмәләр ясау чараларында катнашуга турыдан-туры бәйле булган старт һәм оештыру кертемнәре;

спорт судьялары эшләре;

чәчәкләр сатып алу.

7. Республика, төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә сатып алуларны оештыру «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән чараларны финанслау Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан, шулай ук Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерциягә карамаган башка оешмалар тарафыннан бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан бирелә торган субсидияләр акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.